ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.12.2021 № 1334

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 9 сентябрендәге 825 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Нурлат балалар сәнгать мәктәбе» МБУнең 09.12.2021 ел, 195 номеры белән теркәлгән мөрәҗәгате нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты Уставына таянып

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 9 сентябрендәге 825 номерлы «Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф оешмаларында матди - техник базаны үстерү һәм нығытуга ата-аналарның максатчан кертемнәрен билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-профильле сыйныф - тиешле белгечлек буенча тиешле бүлектә максатчан взносларның билгеләнгән күләменнән 50% күләмендә»;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмаларында матди-техник базаны ныгытуга максатчан ата-аналар кертемнәрен кертү тәртибенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Ятим балалар, инвалид балалар, авыл җирлегендә теркәлгән һәм яшәүче балалар балаларга өстәмә белем бирү муниципаль оешмаларында барлык бүлекчәләрдә дә бушлай белем ала».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә

Җитәкче Р.Р.Хәмзин